

15 октябрьдән 28 октябрьгә кадәр «Евразия» халыкара премиясенә конкурс vтте, ә 29 октябрьдә Мәскәvдә беренче тапкыр «Евразия» халыкара премиясен тапшырдылар. Ул - тарихта халыкара хезмәттәшлекне vстерvгә, традицион кыйммәтләрне саклауга мәдәниятне, мәгарифне, иреклелекне vстерvгә һәм Евразия кинлегендә мәдәни элемтәләрне ныгытуга олеш керткән очен гамәлгә куелган. Конкурска 27 илдән 3700дән артык гариза килгән. Мәскәvгә «Россия» милли vзәгендә финалга узган 1000нән артык катнашучы булган - лауреатлар, экспертлар, җәмәгать эшлеклеләре һәм мактаулы кунаклар.

Конкурста Рузаевка районы Татар Пешләсенен БИТ-21 модель китапханәсендә әйдәп баручы китапханәче Ләйлә Рафаиль кызы Саляева «Җепләр традициясе» хезмәте белән катнашып диплом алды. Анын эш тәҗрибәсе китапханәләрнен мәдәни алмашуны алга сорvдә һәм халыкара анлашуны ныгытуда әһәмиятен ассызыклый. Хәзерге вакытта китапханәләр мәдәни мирасны саклауда һәм алга җибәрvдә топ рольләрне биләvчеләрнен берсе.
«ЕВРАЗИЯ» халыкара премиясе - Евразия континенты илләренен социаль, икътисадый һәм мәдәни vсешенә ярдәм итvче, традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрне саклауга, халык дипломатиясен алга җибәрvгә һәм постсовет кинлеге илләре арасындагы мәгълvмати каршылыкларны җинvгә зур олеш керткән кvренекле шәхесләрне, оешмаларны тануга һәм аларга ярдәм итvгә юнәлдерелгән тарихта беренче халыкара бvләк. Ләйлә Рафаиль кызы әлеге конкурста катнашып тәҗрибә туплады: киләсе елга премияле булыр дип уйлыйбыз.